**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2022 елның 3 феврале 35№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге «2021-2023 елларга Әлки муниципаль районында физик тәрбия һәм спортны үстерү» 518 номерлы озак сроклы район максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль норматив хокукый актны туры китерү белән бәйле рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасы спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты арасындагы «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү турында» килешү һәм Татарстан Республикасының 2021 елның 25 ноябрендәге «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 86-ТРЗ номерлы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге «2021-2023 елларга Әлки муниципаль районында физик тәрбия һәм спортны үстерү» 518 номерлы озак сроклы район максатчан программасына (31.05.2021, 162№ ред.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.1 Программа паспортында «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә

| | |
|---|---|
| **Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары** | Программаны финанслау Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар, билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелгән күләмдә республика бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылачак |

| | |
|---|---|
| | Җирле бюджет:<br>2021 ел-690,4 мең сум.<br>2022 ел-690,4 мең сум.<br>Республика бюджеты:<br>2021 ел - 196,7 мең сум (спорт инвентаре)<br>2022 ел - 197,8 мең сум (спорт инвентаре) |

1.2 Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге «2021-2023 елларга Әлки муниципаль районында физик тәрбия һәм спортны үстерү» 518 номерлы озак сроклы район максатчан программасының 1 нче кушымтасында «2021-2023 елларга физик тәрбия һәм спортны үстерү программасын гамәлгә ашыру чаралары» бүлегенең 19 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № | Чара атамасы | Җаваплы башкаручы | Тормышка ашыру вакыты | Сумма- мең сум | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|
| 19 | Спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура оешмаларын җиһазландыру өчен җиһазлар, инвентарь һәм экипировка сатып алу | Әлки муниципаль районының «Спорт мәктәбе» | 2022 ел | 197,8 | Республика бюджеты |

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге начальнигына йөкләргә.

ТР Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И.В. Юсупов